МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ**

**БОЕРЫК**

31.07.2018

№ **377-пр**

г. Казань

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына гражданнардан коррупция юнәлешендәге фактлар буенча килә торган мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибе турында

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына гражданнардан коррупция юнәлешендәге фактлар буенча килә торган мөрәҗәгатьләр белән эшләүнең тәкъдим ителә торган тәртибен расларга.

2. Билгеләргә:

гражданнардан коррупция юнәлешендәге фактлар буенча килә торган мөрәҗәгатьләрне карау Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында коррупция һәм башка төр хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазыйфаи зат катнашында кадрлар бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла;

гражданнардан коррупция юнәлешендәге фактлар буенча килә торган мөрәҗәгатьләр белән эшләүче вазыйфаи затларга Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт урынындагы мәгълүматны һәм конфиденциаль характердагы мәгълүматларны саклау җаваплылыгы йөкләнә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз карамагымда калдырам.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының ____ ел № ___ боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына гражданнардан коррупция юнәлешендәге фактлар буенча килә торган мөрәҗәгатьләр белән эшләү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясын гамәлгә ашыру максатыннан эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (алга таба – Министрлык) гражданнардан коррупция юнәлешендәге, үз эченә коррупция һәм янап акча алу, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кысу, хезмәткәрләрнең хезмәттәге тәртибенә таләпләр бозылу, шулай ук Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – хезмәткәрләр), шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре булып тормаган һәм Министрлыкта техник тәэмин ителеш һәм хезмәт күрсәтү юнәлешендәге вазыйфаларны биләүче эшчеләр (алга таба – эшчеләр) тарафыннан хезмәт урыныннан файдаланып ярамаган гамәлләр кылуны үз эченә алган башка гамәлләр фактларын алган мөрәҗәгатьләрне карау нечкәлекләрен билгели

Министрлык хезмәткәрләре һәм эшчеләре булмаган башка затларга бәйле коррупция юнәлешендәге фактлар турындагы мәгълүматларны үз эченә алган мөрәҗәгатьләр, «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү алар компетенциясенә карый торган тиешле органга һәм тиешле урындагы затка юлланырга тиеш.

Мөрәҗәгатьтә хокукка каршы гамәлләр әзерләнү, кылыну яки инде кылынган булу турында, шулай ук бу гамәлләрне әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында билгеле булган очракта, мөрәҗәгать, аларның компетенцияләренә туры китерелеп, хокук саклау органнарына юлланырга тиеш.

2. Мөрәҗәгать «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законда билгеләнгән срокларда теркәлә һәм карала.

3. Кадрлар бүлеге тарафыннан хезмәткәргә карата тиешле тәртиптә тикшерү уздырыла. Эшчедән кергән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар буенча язмача аңлатма алына.

4. Мөрәҗәгатьтә коррупцион чагылышлар билгеләре булу турындагы фактлар хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча расланган очракта, министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) материалларны Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча таләпләрне үтәү комиссиясендә карау турында карар кабул итә.

5. Эшчегә карата әлеге фактлар расланган очракта, җыелган материаллардан һәм аның язма аңлатмаларын анализлаудан чыгып, аңа карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану мәсьәләсе хәл ителә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча хокукка каршы гамәлләр әзерләнү, кылыну яки инде кылынган булу турында, шулай ук бу гамәлләрне әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында билгеле булган очракта, мондый мәгълүмат, аларның компетенцияләренә туры китерелеп, хокук саклау органнарына юлланырга тиеш.

6. Мөрәҗәгать юллаган гражданинга җавап Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының коррупция һәм башка төр хокук бозуларны кисәтү буенча җаваплы вазыйфаи зат (алга таба – вазыйфаи зат) тарафыннан әзерләнә.

Мөрәҗәгатьне карауда катнашкан затлар вазыйфаи затка гражданинга җавап юллау срогы чыгарга 15 көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать буенча язма тәкъдимнәр юллыйлар

7. Мөрәҗәгатьтә вазыйфаи затка мөнәсәбәттә коррупцион юнәлештәге мәгълүматлар булган очракта, вазыйфаи зат бу мөрәҗәгатьне карауда үзе катнашмый.